КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 46

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2.Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 август, 783 нче карары белән расланган «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2.Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2.Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 август, 783 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 октябрь, 947 нче; 2022 ел, 1 август, 742 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Алабуга-2. Нефтехимия» идарәче компаниясе» җаваплылыгы

чикләнгән җәмгыятенә «Алабуга-2.Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Агымдагы финанс елында субсидия алу өчен заявка бирүче, агымдагы финанс елының 20 декабреннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка түбәндәге документларны (алга таба – заявка) тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә гариза (шул исәптән заявка бирүченең субсидия бирүгә бәйле мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгы бирелә);

салым органының Килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата бирелгән, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча заявка бирүченең бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазен;

заявка бирүченең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кире

кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча вакытында түләнәмәгән (җайга салынмаган) бурычлары булмавы, шулай ук бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавы турында заявка бирүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган белешмә кәгазен;

заявка бирүченең үзгәртеп оештыру (заявка бирүчегә башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, заявка бирүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында заявка бирүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган белешмә кәгазен;

заявка бирүченең чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавы турында заявка бирүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган белешмә кәгазен;

заявка бирүченең уставы күчермәсен;

заявка бирүченең җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1 енче көненә карата бирелгән белешмә;

«Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының финанс-икътисад моделен, мастер-планын үз эченә алган бизнес-план, Министрлык тарафыннан расланган форма нигезендә һәр капиталь төзелеш объекты буенча эш башкару срокларын үз эченә алган җентекле план-график;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрен формалаштыру (аларга үзгәреш кертү) һәм федераль бюджет акчасы белән баш эш имтүчеләр тарафыннан кертү тәртибе турында» 2021 елның 17 июнендәге 86н номерлы боерыгы белән расланган Бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрен формалаштыру (аларга үзгәреш кертү) һәм федераль бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан кертү тәртибенең 171 нче кушымтасында бирелгән форма буенча «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының комплекслы инвестиция проекты паспорты күчермәләрен теркәп, 1119 нчы карарның II бүлегендәге 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашыру чоры, графигы һәм «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының финанс-икътисадый күрсәткечләре карала торган хезмәттәшлек турында килешү;

индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре реестрыннан «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының һәм заявка бирүченең 794 нче карарда билгеләнгән индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренә карата таләпләргә туры килү турында өземтә;

проект-тикшерү эшләре өчен эшләрне тапшыру-кабул итү, авторлык күзәтчелеге, төзелеш контроле актлары күчермәләрен;

проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм капиталь ремонтлауның смета кыйммәтен билгеләүгә дәүләт экспертизасы үткәрү эшләрен тапшыру-кабул итү актлары күчермәләрен;

парклар инфраструктурасы объектларының техник шартларын эшләүгә һәм аларны технологик тоташтыруга актлар күчермәләрен;

КС-3 формасы буенча «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча башкарылган эшләр кыйммәте һәм аларның чыгымнары турында белешмә кәгазьләре күчермәләрен (башкарылган төзелеш-монтаж эшләре булган очракта);

КС-2 формасы буенча «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләрен (башкарылган төзелеш-монтаж эшләре булган очракта);

УПД формасы буенча җиһазларны кабул итү-тапшыру турында актлар һәм ОС-15 формасы буенча җиһазларны монтажга кабул итү-тапшыру турында актлар күчермәләрен (КС-2 формасы буенча «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында рәсмиләштерелгән актлар булмаган очракта);

«Алабуга-2» индустриаль паркының инфраструктура объектлары буенча подряд оешмасы белән төзелгән шартнамәләр күчермәләрен;

башкарылган эшләргә түләүне һәм (яки) сатып алынган җиһазларга түләүне раслый торган түләү документлары һәм (яки) башка документлар күчермәләрен;

проект документациясенә һәм мондый проект документациясен әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәләрен (башкарылган төзелеш-монтаж һәм проект-тикшеренү эшләре булган очракта);

төзелеш объектларының смета кыйммәте дөреслеге турында дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәләрен;

дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе белән расланган объектларны төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисаплары күчермәләрен;

объектларны төзүнең, модернизацияләүнең һәм (яки) реконструкцияләүнең проект-смета документациясе күчермәләрен;

һәр субсидияләнә торган төзелеш, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү объекты буенча исемен, кыйммәтен, сорала торган субсидия күләмен, тапшырылган җыелма смета исәп-хисаплары кысаларында элек бирелгән субсидия күләмен

күрсәтеп, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмә кәгазен.

Заявка бирүче тарафыннан бу пунктның икенче һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка бирүче Министрлыкка бу пунктның егерме дүртенче абзацында күрсәтелгән документларны электрон чыганакта сканерланган рәвештә тапшырырга хокуклы.

Бу пунктның унөченче – унсигезенче абзацларында күрсәтелгән документлар заявка бирүче тарафыннан тапшырыла, аңа тапшырылган документларның дәүләт экспертизасыннан уңай бәяләмә бирелгән проект (смета) документларына туры килүен раслый торган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хаты теркәлә.»;

12 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән җиде эш көне эчендә заявка бирүче белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи. Килешү «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының комплекслы инвестиция проекты паспорты нигезендә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган срогына тиң булган срокка төзелә.»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Килешү гамәлдә булган чорда заявка бирүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасына теркәлгән кушымта нигезендә Килешүгә өстәмә килешү төзү өчен бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче – алтынчы, унөченче – егерме бишенче абзацлары нигезендә документлар тапшырырга хокуклы.

Комплекслы инвестиция проекты паспортына үзгәрешләр кертелгән (проект нәтиҗәләре күрсәткечләрен арттырган, проектны гамәлгә ашыру срокларын һәм (яки) инфраструктура исемлеген үзгәрткән) очракта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасына теркәлгән кушымта нигезендә Килешүгә өстәмә килешү төзелә.

Кирәк булганда Министрлык һәм заявка бирүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасына теркәлгән кушымта нигезендә Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

15 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 7 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән юнәлешләр буенча өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча фактта тотылган, бу Тәртипнең 8 пунктындагы унөченче – унсигезенче абзацларында күрсәтелгән документлар белән расланган чыгымнар.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидияләр бирү нәтиҗәләренең еллык план күрсәткечләре «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркының комплекслы инвестиция проекты паспортында билгеләнә һәм «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашырып бетерү датасына түбәндәге күрсәткечләргә туры килә:

2026 елның 31 декабренә югары җитештерүчәнлекле эш урыннары саны – «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашыра башлаганнан алып кимендә 10 394 эш урыны;

2026 елның 31 декабренә «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы резидентлары саны (җыелган йомгак белән) – «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашыра башлаганнан алып кимендә 11 резидент;

«Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы резидентларының җыелма кереме – кимендә 187,28 млрд.сум;

2026 елның 31 декабренә федераль бюджет һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итү исәбеннән «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы инфраструктурасын булдыруны финанслау буенча гамәлгә ашырылган һәм планлаштырыла торган җыелма күләменә карата 2026 елга «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы резидентларының җыелма кереме нисбәте коэффициенты («Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы проектын гамәлгә ашыра башлаганнан алып җыелган йомгак белән, бюджетара трансфертларны исәпкә алмыйча) – кимендә 8;

2026 елга исәпләнгән, «Алабуга-2. Нефтехимия» индустриаль паркы территориясендә алына торган җыелма өстәлгән кыйммәт – кимендә 82,51 млрд.сум.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин